Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге

Кадрәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**14.11.2025** **№ 1**

Гамәлдәге законнар нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, 2025 елның 14 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта "Әгерҗе муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадрәк торак пункты территория-сендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәр-би операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мо-билизацияләнгәннәр, ирекллеләр ) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан ( бергә яшәүче ата-аналары, ирләре яки хатыннары, балигъ булган балалары), I төр-кем инвалидлардан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшьтәге һәм ан-нан өлкәнрәкләрдән), көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясенә хәрби хезмәткә чакырылган һәм иректән мәхрүм итү урыннарын-дагы затлардан тыш), 2026 елда үзара салым акчасын 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Кадрәк авылының Ленин, Нарат, Басу, Елга аръягы, Яшьләр урамнарына вак ташлар сатып алу һәм салу);
- торак пункты чикләрендә җәяүлеләр күперләрен, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларына кермәгән җәяүлеләр өчен җир өсте юлларын ремонтлау (Кадрәк авылы авыл җирлеге чикләрендәге күперләрне ремонтлау һәм карап тоту);
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасын йөртүчегә түләү);
- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, дроссельләр, фонарьлар, электр товарлары һәм урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу һәм алмаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);
- халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерү һәм торак

пунктның аларга якын территорияләрен төзекләндерү (кышын Ленин, Басу, Яшьләр, Елга аръягы, Нарат урамнары буенча юлларны чистарту), тракторны тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, мәдәният йорты, ФАП, административ бина коймаларын ремонтлау, төзекләндерү буенча башка чыгымнар;

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; сантехник һәм чыгым материаллары, насослар сатып алу, сууткәргеч челтәрен ремонтлау һәм Кадрәк торак пунктында су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар;

башкаруга юнәлтүгә, кулланугa ризамы?” дигән сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

« РИЗА» «КАРШЫ».

Беркетмә нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 302 катнашучы кертелде. Гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 165 кеше, бу 54,6% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 165 катнашучысы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирүчеләр юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадрәк торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Әгерҗе муниципаль районы «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадрәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекле хезмәткәрләр ) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан ( бергә яшәүче ата-аналары, ире яки хатыны, балигъ булган балалары), Iтөркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшькә җиткәннәр), көндезге формада укучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш) 2026 елда үзара салым акчаларын 1000 сум күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Кадрәк авылының

Ленин, Нарат, Басу, Елга аръягы, Яшьләр урамнарына вак ташлар сатып алу һәм салу);

- торак пункты чикләрендә җәяүлеләр күперләрен, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларына кермәгән җәяүлеләр өчен җир өсте юлларын ремонтлау (Кадрәк авылы авыл җирлеге чикләрендәге күперләрне ремонтлау һәм карап тоту);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасын йөртүчегә түләү);

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, дроссельләр, фонарьлар, электр товарлары һәм урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу һәм алмаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

- халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерү һәм торак пунктның аларга якын территорияләрен төзекләндерү (кышын Ленин, Басу, Яшьләр, Елга аръягы, Нарат урамнары буенча юлларны чистарту), тракторны тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, мәдәният йорты, ФАП, административ бина коймаларын ремонтлау, төзекләндерү буенча башка чыгымнар;

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; сантехник һәм чыгым материаллары, насослар сатып алу, суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм Кадрәк торак пунктында су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар;

4.Карарны Кадрәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы сайтында (https://agryz.tatarstan.ru), «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә .

Гражданнар җыенында рәислек итүче
авыл җирлеге башлыгы А.А.Михайлов